КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 10 сентябрь г.Казань № б-1732

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 11 октябрь, б-2658 нче боерыгына, аңа түбәндәге эчтәлекле 4 нче пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Бу боерыкның гамәле Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 маендагы б-1063 номерлы боерыгы нигезендә акчасы күпфатирлы йортлар төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертелгән гражданнарның проблемаларын хәл итү чараларын гамәлгә ашыру буенча план-графикка («юл картасы»на) кертелгән, төзелешен тәмамлап бетерүне финанслау Татарстан Республикасының Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды катнашында «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы кысаларында гамәлгә ашырыла торган торак йортларга кагылмый дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин